ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 12 12.03.2024 ел

*2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 7 санлы, 2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 8 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында*

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урал бистәсе, Урал урамы, 10В йорт адресы буенча урнашкан күп функцияле үзәк бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында 2023 елның 24 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 7 санлы, 2023 елның 24 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 8 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез эшләнәсе эшләрне түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урале торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 7

санлы, 2023 елның 24 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 8 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

«1) Урал торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (зират территориясен коймаларны ремонтлау (төзү материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү));

2) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урал торак пунктын грейдерлау, юлларны кардан чистарту)»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы ______________ А.Г. Дәүләтгәрәев
(имза)